ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
28.06.2024

**К А Р А Р**
№ 587

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында муниципаль заказчылар, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләр ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру вәкаләтле органы һәм тәртибе турында» 2014 елның 31 мартындагы 351 номерлы карарын гамәлгә ашыру хакында» 2014 елның 14 апрелендәге 663 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында муниципаль заказчылар, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләр ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру вәкаләтле органы һәм тәртибе турында» 2014 елның 31 мартындагы 351 номерлы карарын гамәлгә ашыру хакында» 2014 елның 14 апрелендәге 663 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-«Муниципаль заказчылар, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмә» дип аталган 2 нче кушымтаның 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4 Сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәгә, сатып алу турындагы документларга (сатып алу турындагы документлар 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракта), конкурста катнашуга заявкаларга эксперт бәясе уздыруга экспертлар буларак җәлеп ителгән физик затлар; тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынуы булган физик затлар, шул исәптән тәэмин

итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашуга гариза биргән, йә әлеге заявкаларны биргән оешмалар яисә физик затлар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы, йә тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашуга гариза биргән оешмалар идарәчесе булып торган физик затлар; сатып алуда катнашуга заявка биргән оешмаларның катнашучылары (акционерлары), аларның идарә органнары әгъзалары, сатып алуларда катнашучыларның кредиторлары булган физик затлар; 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән сатып алулар өлкәсендә турыдан-туры контрольне гамәлгә ашыручы контроль органнарының вазыйфаи затлары комиссия әгъзалары була алмый.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин